ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **К А Р А Р**

24.12.2024 | № 1153

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Яңа ел бәйрәмнәренә биналар территорияләрен һәм фасадларын иң яхшы бизәүгә конкурс уздыру турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы биналары территорияләрен һәм фасадларын эстетик бизәлешен яхшырту һәм Яңа ел бәйрәмнәренә багышланган чаралар үткәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 25 декабреннән 2025 елның 14 гыйнварына кадәр Яңа ел бәйрәмнәренә биналар территорияләрен һәм фасадларын иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс үткәрергә.

2. Расларга:

2.1. Биектау муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре территорияләренең иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә.

2.2. Яңа ел бәйрәмнәренә биналар территорияләрен һәм фасадларын иң яхшы бизәлешенә конкурста җиңүчене билгеләү өчен эшче комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә.

2.3. Яңа ел бәйрәмнәренә территорияләр һәм биналар фасадларын иң яхшы бизәлешенә конкурста катнашу өчен заявканы 3 нче кушымта нигезендә.

3. Эшче комиссиягә 2025 елның 15 гыйнварына кадәр конкурска йомгаклар ясарга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы БК 2024 елның
24 декабрендә 1153нче
номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре территорияләренең иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс уздыру тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары:

1) Яңа ел бәйрәмнәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүчеләр өчен бәйрәм атмосферасы булдыру;

2) биналарның, урамнарның, мәйданнарның, чыршыларның сәнгатьчә, яктылык бизәлешен яхшырту.

**2. Конкурста катнашучылар**

2.1. Конкурста авыл җирлекләре советлары, бюджет учреждениеләре һәм физик затлар катнаша.

**3. Конкурс шартлары**

3.1. Конкурста катнашучыларга аларга беркетелгән территорияләрне һәм биналарны Яңа ел тематикасы нигезендә, янгынга каршы һәм гомуми куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәп, матур итеп бизәргә кирәк.

3.2. Конкурста җиңүче аның нәтиҗәләре буенча ул җиңүче дип табылган конкурсны үткәргәннән соң бер елдан соң гына яңадан конкурста катнашучы була ала.

**4. Конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе**

4.1. Конкурста катнашалар:

1) Биектау муниципаль районының бюджет оешмалары (Биектау һәм Красносельский җирлекләре территориясендә урнашкан бюджет оешмаларыннан тыш);

2) Биектау муниципаль районы Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләренең бюджет оешмалары;

3) физик затлар.

4.2. Конкурста катнашу өчен гаризалар 2024 елның 25 декабреннән 2025 елның 14 гыйнварына кадәр 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча электрон почтага: biektau@tatar.ru кабул ителә

4.3. Гаризага конкурска куелган объектның электрон рәвештә кимендә ике, ләкин алтыдан да артык булмаган электрон формада фотографияләре беркетелә.

4.4. Эшче комиссия 2024 елның 25 декабреннән 2025 елның 14 гыйнварына кадәр конкурста җиңүчеләрне билгеләү максатында Биектау муниципаль районын йөреп чыгачак. Конкурс йомгаклары 2025 елның 15 гыйнварына ясала.

## 5. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү критерийлары

5.1. Конкурсны бәяләүнең төп критерийлары түбәндәгеләр:

1) Яңа ел бизәлешенең сәнгать дәрәҗәсе;
2) котлау язулары булу;
3) яктылык-иллюминация бизәлеше;
4) бизәлеш оригинальлеге, инновацион якын килү;
5) кар яисә боз фигуралары, горкалар, боз шәһәрчекләре булу;
6) 2025 ел символы стилистикасында бизәү.

## 6. Җиңүчеләрне билгеләү

6.1. Җиңүчеләр район Советы карары белән расланган комиссия тарафыннан билгеләнә.

6.2. Конкурс таләпләренә һәм шартларына туры килә торган катнашучылар конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү кәгазьләре нигезендә әлеге Нигезләмәнең 5.1 п. билгеләнгән критерийлар нигезендә 5 баллы шкала буенча бәяләнә. Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

6.3. Иң күп тавыш җыйган катнашучы бәйгедә җиңүче дип санала. Җиңүчеләрне билгеләү биш номинация буенча башкарылачак, һәр номинациядә өчәр призлы урын.

## 7. Призлар фонды

**«2024 елның 25 декабреннән 2025 елның 14 гыйнварына кадәр чорда Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре арасында территорияне иң яхшы бизәлеш һәм яңа ел чараларын уздыру (Биектау һәм Красносельский җирлекләреннән тыш)» исеменә муниципаль конкурс**

1 нче урын - 80 мең сум;
2 нче урын – 60 мең сум;
3 нче урын – 40 мең сум.

**«Биектау муниципаль районы бюджет оешмалары арасында иң яхшы яңа ел бизәлеше (Биектау һәм Красносельский җирлекләре**

**территориясендә урнашкан бюджет оешмаларыннан тыш)» исеменә муниципаль конкурс**

1 нче урын - 80 мең сум;
2 нче урын – 60 мең сум;
3 нче урын – 40 мең сум.

**«Биектау муниципаль районы Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре бюджет оешмалары арасында иң яхшы яңа ел бизәлеше» исеменә муниципаль конкурс**

1 нче урын - 80 мең сум;
2 нче урын – 60 мең сум;
3 нче урын – 40 мең сум.

**«Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ишегалдының иң яхшы яңа ел бизәлеше» исеменә муниципаль конкурс»**

1 нче урын - 30 мең сум;
2 нче урын – 20 мең сум;
3 нче урын – 10 мең сум.

**БАРЛЫГЫ: 600 мең сум**

Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча уздырыла.

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы БК 2024 елның
24 декабрендә 1153нче
номерлы номерлы карары
белән расланды

**Яңа ел бәйрәмнәренә биналарның территорияләрен һәм фасадларын иң яхшы бизәүгә конкурста җиңүчене билгеләү өчен эшче комиссия составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәкимуллин Рамил Фатихович | - Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| 2. | Сабирҗанов Ринат Рәшитович | - Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Камалов Фәрхад Шамилевич | - башкарма комитетның мәдәният бүлеге башлыгы; |
| 4. | Хисамутдинов Рөстәм Шәүкәтович | - Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы; |
| 5. | Мостафина Эльвира Әнвәровна | - «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры, «Биектау хәбәрләре» газетасы редакциясе; |
| 6. | Халитов Илсур Әхмәтсафиевич | - Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - РОО башлыгы; |
| 7. | Чапурин Станислав Михайлович | - Биектау муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы. |

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы БК 2024 елның
24 декабрендә 1153нче
номерлы номерлы карары
белән расланды

**Биектау муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре территорияләрен, фасадларын иң яхшы яңа ел бизәлеше конкурсында катнашуга заявка**

Биектау муниципаль районы оешмалары һәм
учреждениеләре территорияләрен, фасадларын
иң яхшы яңа ел бизәлеше конкурсы
нәтиҗәләрен ясау комиссиясе рәисе,
Башкарма комитет җитәкчесе
Р.Ф. Хәкимуллинга

Мин,

______________________________________________________________,

Оешма җитәкчесенең Ф.И.А.

______________________________________________________________

(предприятие, оешманың тулы атамасы)

______________________________________________________________

(Вазыйфасы, эш урыны)

Сездән______________________________________________________

______________________________________________________________

номинациясендә Биектау муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре территорияләренең иң яхшы яңа ел бизәлеше конкурсында катнашуга заявканы кабул итүегезне сорыйм.

Оешма/учреждениенең почта һәм факттагы адресы ____________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Контакт телефоны: ___________________________________________

Кушымта: конкурска куела торган объектның электрон рәвештә фотосы, 2 - 6 данә.

Дата Гариза бирүченең имзасы